**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**
**Сатмыш авыл җирлеге Советы**

**Карары**

2020 ел,17 февраль №194

**Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Сатмыш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Сатмыш авыл җирлеге Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирлекнең генераль планнарын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документларны раслау, җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Сатмыш авыл җирлеге Советына:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Сатмыш авыл җирлеге Советының 2020 елга һәм 2021 ,2022 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Сатмыш авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр керту хакындагы,бюджет законнары нигезендә карар проектын эшләргә һәм тикшерергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Сатмыш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы**
**Сатмыш авыл җирлеге Башлыгы** **Р.Р.Сибгәтова**